**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Лаишевский муниципальный район**
**Муниципальное учреждение**
**Исполнительный комитет**
**Чирповского сельского поселения**
422615 с. Чирпы
тел: 8-(84378) -2-91-45
факс: 8-(84378) -2-91-45
Эл. Адрес Chirp.La @tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Лаеш Муниципаль районы**
**Чирпы авыл җирлеге башкарма**
**комитеты муниципаль**
**учреждениесе**
422615 а. Чирпы
тел: 8-(84378) --2-91-45
факс: 8-(84378) -2-91-45
Эл. адрес: Chirp.La @tatar.ru

**№6** **2019 елның 15 апреленнән**

**КАРАР**

**Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

2010 елның 27 июленнән № 210-ФЗ “Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне оештыру турында”гы Федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2010 елның 2 ноябреннән №880 “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында”гы карарына, Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2010 елның 13 ноябреннән №2027 “Лаеш муниципаль районы муниципаль хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау турында”гы карарына ярашлы төстә **карар бирәм**:

1. Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (Кушымта) расларга.
2. Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырырга (халыкка чыгарырга).
3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 15 августыннан №11 “Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы карарын көчен югалткан дип табарга.
4. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне Чирпы авыл җирлеге Башкарма комитетыҗитәкчесе Р.А.Евдокимовка йөкләргә.

**Чирпы авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.А.Евдокимов**